| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.09.2021 с. Сарманово № 272

Сарман муниципаль районы территориясендә
табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне
ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1996 елның 10 ноябрендәге 1340 номерлы карары, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервларын булдыру һәм куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы карарына нигәзләнеп (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 22 июлендәге 640 номерлы карары редакциясендә)

КАРАР БИРӘМ

1. Расларга

1.1. Сарман муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервлары турында нигезләмә (1 нче кушымта);

1.2. Сарман муниципаль районы техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар номенклатурасы һәм күләме (2 нче кушымта);

2.Сарман муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервларын булдыру буенча җитәкчелек итүне һәм аны координацияләүне Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

3. Сарман муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары җитәкчеләренә, җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

3.1. Ведомство карамагындагы объектларда җирле һәм объект дәрәҗәсендәге